# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
«Кыр Шонталы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
Кече Кызыл Яр авыл торак пунктында
2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**2025 елның 24 октябреннән** **№ 2**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына туры китереп, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Кыр Шонталы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кече Кызыл Яр торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2026 елда Алексеевск муниципаль районының «Кыр Шонталы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Кече Кызыл Яр торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш.

2.Җыелган акчаларны жирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пункт территориясен төзекләндерү;
- ремонт, коймалар кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү;

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта Кыр Шонталы авыл жирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт бирергә.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен, кабул ителгән көннән 10 көн эчендә Кыр Шонталы авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка житкерергә, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында

(http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Кыр Шонталы авыл җирлеге башлыгы ______________ Кыямова Г.Н.
(имза)